**КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ**

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2017 ел, 22 февраль № 113

г. Казань

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында җирле үзидарәне формалаштыруга һәм үстерүгә булышлык күрсәтүгә юнәлдерелгән чараларны гамәлгә ашыручы коммерциягә карамаган оешмаларга Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр бирү тәртибен раслау турында» 2011 ел, 24 август, 706 нчы карары белән расланган Татарстан Республикасында җирле үзидарәне формалаштыруга һәм үстерүгә булышлык күрсәтүгә юнәлдерелгән чараларны гамәлгә ашыручы коммерциягә карамаган оешмаларга Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр бирү тәртибенә үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында җирле үзидарәне формалаштыруга һәм үстерүгә булышлык күрсәтүгә юнәлдерелгән чараларны гамәлгә ашыручы коммерциягә карамаган оешмаларга Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр бирү тәртибен раслау турында» 2011 ел, 24 август, 706 нчы карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2015 ел, 30 декабрь, 1032 нче карары белән кертелгән үзгәрешне исәпкә алып) расланган Татарстан Республикасында җирле үзидарәне формалаштыруга һәм үстерүгә булышлык күрсәтүгә юнәлдерелгән чараларны гамәлгә ашыручы коммерциягә карамаган оешмаларга Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр бирү тәртибенә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

2 нче пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2. Субсидияләр Татарстан Республикасында җирле үзидарәне формалаштыруга һәм үстерүгә, шул исәптән Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре халкының социаль һәм икътисадый проблемаларын хәл итүгә булышлык күрсәтүгә юнәлдерелгән чараларны гамәлгә ашыру белән бәйле чыгымнарны финанслар белән тәэмин итү максатларында бирелә.»;

3.1 нче пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3.1. Субсидияләр дәүләт (муниципаль) учреждениеләре булмаган, субсидия бирү турында килешү төзергә планлаштырыла торган айга кадәр килгән айның беренче көненә түбәндәге таләпләргә туры килә торган коммерциягә карамаган оешмаларга бирелә:

субсидия алучылар эшчәнлекләрен Татарстан Республикасы территориясендә гамәлгә ашыра;

субсидия алучыларның Россия Федерациясе законнары нигезендә үтәү вакыты җиткән Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетларына салымнар, җыемнар һәм башка мәҗбүри түләүләр буенча бурычлары булмаска тиеш;

субсидия алучыларның Россия Федерациясе бюджет системасының тиешле бюджетына субсидияләр, бюджет инвестицияләре (шул исәптән башка хокукый актлар нигезендә бирелгән) кайтару буенча вакыты чыккан бурычлары һәм Россия Федерациясе бюджет системасының тиешле бюджетына башка вакыты чыккан бурычлары булмаска тиеш;

субсидия алучылар үзгәртеп оештыру, ябылу, банкротлык процессында булмаска тиеш һәм аларның хуҗалык эшчәнлеген гамәлгә ашыруга чикләүләре булмаска тиеш;

субсидия алучылар теркәлү урыны Россия Федерациясе Финанс министрлыгы раслый торган салым салуның ташламалы салым режимы бирә торган һәм (яки) мондый юридик затларга карата финанс операцияләре үткәргәндә мәгълүмат ачу һәм бирү күздә тотылмаган дәүләтләр һәм территорияләр (офшор зоналар) исемлегенә кертелгән дәүләт яки территория булган устав (җыелма) капиталларындагы чит ил юридик затлары катнашу өлеше барысы бергә 50 проценттан арткан чит ил юридик затлары, шулай ук Россия юридик затлары булмаска тиеш;

субсидия алучылар Россия Федерациясе бюджет системасының тиешле бюджетыннан башка норматив хокукый актлар, муниципаль хокукый актлар нигезендә әлеге Тәртипнең 2 нче пунктында күрсәтелгән максатларга акча алучылар булмаска тиеш.»;

3.2 нче пунктта:

бишенче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«салым органыннан субсидия алучының Россия Федерациясе законнары нигезендә үтәү вакыты җиткән Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетларына салымнар, җыемнар һәм башка мәҗбүри түләүләр буенча бурычлары булмауны раслый торган белешмә;»;

түбәндәге эчтәлекле абзацлар өстәргә:

«Россия Федерациясе законнары нигезендә үтәү вакыты җиткән Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетларына салымнар, җыемнар һәм башка мәҗбүри түләүләр буенча бурычлар, шулай ук Россия Федерациясе бюджет системасының тиешле бюджетына вакыты чыккан бурычлар булмауны раслый торган документ;

субсидия алучының ябылу, банкротлык процессында тормавы һәм хуҗалык эшчәнлеген гамәлгә ашыруга чикләүләре булмавы турында субсидия алучының җитәкчесе имзалаган гарантия хаты.»;

3.4 нче пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3.4. Коммерциягә карамаган оешмага субсидия бирүдән баш тарту өчен түбәндәгеләр нигез булып тора:

субсидия алучының әлеге Тәртипнең 3.1 нче пункты таләпләренә туры килмәве;

әлеге Тәртипнең 3.2 нче пунктында каралган документларны тапшырмау (тулы күләмдә тапшырмау);

субсидия алучы тапшырган әлеге Тәртипнең 3.2 нче пунктында күрсәтелгән документларда һәм гаризадагы мәгълүматларның дөрес булмавы.»;

түбәндәге эчтәлекле 3.6 нчы пункт өстәргә:

«3.6. Субсидия күләме Татарстан Республикасында җирле үзидарәне формалаштыруга һәм үстерүгә, шул исәптән Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре халкының социаль һәм икътисадый проблемаларын хәл итүгә булышлык күрсәтүгә юнәлдерелгән чараларны гамәлгә ашыру белән бәйле түбәндәге чыгымнар суммасы буларак билгеләнә:

эш хакына исәпләнә торган иминият кертемнәрен исәпкә алып, хезмәткәрләрнең хезмәте өчен түләү;

бәйсез экспертларның, штаттан тыш хезмәткәрләрнең хезмәте өчен түләү;

чараларны матди-техник тәэмин итү;

төп чаралар сатып алу;

эшләр һәм хезмәт күрсәтүләр өчен түләү.»;

4 нче пунктта:

беренче абзацка «Министрлык раслаган бертип форма буенча» сүзләрен өстәргә;

икенче абзацка «аны бирү тәртибе» сүзләреннән соң «, алынган акча исәбеннән чит ил валютасы алуны тыю, Россия Федерациясе валюта законнары нигезендә югары технологияле импорт җиһазлары, чимал һәм комплектлау җайланмалары сатып алганда (кайтартканда) гамәлгә ашырыла торган операцияләрдән, шулай ук әлеге Тәртиптә билгеләнгән акчаны бирү максатларына ирешүгә бәйле башка операцияләрдән тыш» сүзләрен өстәргә;

7 нче пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«7. Субсидияләр түбәндәге очракларда субсидия алучылар тарафыннан Министрлыкның тиешле таләбен алган көннән соң 30 көн эчендә Татарстан Республикасы бюджетына кире кайтарылырга тиеш:

субсидия алучы дөрес булмаган мәгълүматлар һәм документлар бирсә;

субсидия алучының әлеге Тәртиптә билгеләнгән шартларны бозу фактлары ачыкланса.».

Татарстан Республикасы
Премьер-министры И.Ш.Халиков

F:\KARAR\2017\113.doc